Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылы гражданнарының 2023 елда үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ КАРАРЫ

2022 елның 20 октябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылы гражданнар җыены нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, инвалидлардан, 1 төркем инвалидлардан һәм 75 яшьтән олырак ялгыз яшәүче гражданнар тыш.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Чишмә, Я, Х. Хәйруллин, Үзәк урамнары, тыкрыклар буенча материал сатып алу ,ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- зират территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен һәм үсемлекләрне чабу юк итү өчен агу сатып алу, корыган агачларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү);

- «Наил бабай чишмәсе» территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен һәм үсемлекләрне чабу,юк итү өчен агу сатып алу, корыган агачларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/,» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г. Гаризов